**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. Советская, д.80, с. Новошешминск,423190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**Совет урамы, 80, Яңа Чишмә авылы,423190**

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советы КАРАРЫ

2020 елның 4 сентябре №63-398

"Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүчеләрнең, контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларына акчалата түләүләр күләмен арттыру турында"

«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата түләүләр, Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 12 апрелендәге 35-197 номерлы карары (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2018 елның 26 июнендәге 39-218 номерлы, 29.04.2020 №60-375 карарларындагы үзгәрешләр белән) белән расланган даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә ай саен акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкыр арттырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (http//pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http//novosheshminsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы В.М. Козлов